ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 26 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяга түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:
«$5^1$) гадәттән тыш хәл аркасында зыян күргән гражданнарның дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм алу хокукын гамәлгә ашыруны тәэмин итү тәртибен һәм шартларын раслау;»;

2) 12 статьяда:
а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $8^1$ пункт өстәргә:
«$8^1$) гадәттән тыш хәл аркасында зыян күргән гражданнар:
а) гадәттән тыш хәл аркасында һәлак булган (вафат булган) затның һәлак булу (вафат булу) көненә аның белән теркәлгән никахта торучы ире (хатыны);
б) гадәттән тыш хәл аркасында һәлак булган (вафат булган) затның балалары;
в) гадәттән тыш хәл аркасында һәлак булган (вафат булган) затның ата-анасы;
г) гадәттән тыш хәл аркасында һәлак булган (вафат булган) затның тулаем каравында булган яисә яшәр өчен даими һәм төп керем чыганагы рәвешендә аннан ярдәм алып торган затлар, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә аның тәрбиясендәге затлар дип танылган бүтән затлар;
д) гадәттән тыш хәл аркасында сәламәтлегенә зыян килгән гражданнар;

е) гадәттән тыш хәл аркасында торак урыныннан мәхрүм калган йә тулысынча яисә өлешчә бүтән мөлкәтен йә документларын югалткан гражданнар;»;

б) 2 өлештә:

7 пунктта «бәйле рәвештә» сүзләреннән соң «яисә гадәттән тыш хәл аркасында» сүзләрен өстәргә;

9 пунктта «хезмәт пенсияләре» сүзләрен «иминият пенсияләре» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәргә:

«16) гадәттән тыш хәл аркасында бозылган мөлкәти хокукларын, мөлкәти булмаган шәхси хокукларын торгызу, гадәттән тыш хәл аркасында килгән зыянны түләү.»;

в) 3 өлештә:

2 пунктның «б» пунктчасында «бәйле рәвештә» сүзләреннән соң «яисә гадәттән тыш хәл аркасында» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) гадәттән тыш хәл аркасында зыян күргән гражданнар булсалар – гадәттән тыш хәл аркасында бозылган мөлкәти хокукларын, мөлкәти булмаган шәхси хокукларын торгызуга, гадәттән тыш хәл аркасында килгән зыянны түләүгә бәйле мәсьәләләр буенча.»;

г) түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«4. Гадәттән тыш хәл аркасында зыян күргән гражданнарның дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм алу хокукын гамәлгә ашыру тәртибе, шартлары һәм аны оештыру-хокукый тәэмин итү Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, әлеге Закон, Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары белән җайга салына.».

**2 статья**

Әлеге Закон, 2015 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 статьяның 2 пунктындагы «б» пунктчасыннан гайре, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2014 елның 15 декабре
№ 117-ТРЗ